ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**АКБАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
БАШЛЫГЫ
423958 Ютазы районы,
Акбаш авылы, Мәктәп урамы, 17
тел. 4-14-34
факс: 8 (85593) 4-14-34

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
**АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
423958 Ютазинский район
село Акбаш ул.Школьная, д.17
тел. 4-14-34
факс: 8 (85593) 4-14-34

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» октябрь 2024 ел № 3

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге составына керүче Акбаш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставының 26 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 23 сентябрендәге 15 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында"гы Нигезләмәсенә ярашлы, КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 15 ноябрендә 15.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Акбаш авылы, Мәктәп урамы, 17 йорт адресы буенча урнашкан Акбаш торак пунктының КФҮ бинасында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнар тыш, 2025 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә сез ризамы:

- Акбаш торак пунктында каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары төзү (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү);

- Акбаш торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны грейдерлау һәм кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)».

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге башкарма комитетына Акбаш торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru / электрон адресы буенча кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге башлыгы И.Р.Сәхибуллина